**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2021 елның «14» апреле** **1025 номер**

# КАРАР

**Кадастр номерлары16:24:190502:1238, 16:24:190502:1239, 16:24:190502:1240, 16:24:190502:1241, 16:24:190502:1242, 16:24:190502:1243, 16:24:190502:1244 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектын әзерләү турында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 42, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, гомуми файдалану территорияләре чикләрен, планлаштырылган капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү, территорияне планлаштырыла торган үстерү характеристикаларын һәм чиратлылыгын билгеләү максатларында карар бирәм:

1. Кадастр номерлары 16:24:190502:1238, 16:24:190502:1239, 16:24:190502:1240, 16:24:190502:1241, 16:24:190502:1242, 16:24:190502:1243, 16:24:190502:1244 булган җир кишәрлекләр белән е чикләнгән территорияне ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.
2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42 статьясы нигезендә билгеләргә.
3. Гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2021 ел ахырына кадәр билгеләргә.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга территорияне планлаштыру проекты тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә йөкләргә.
6. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб – адрес буенча һәм интернет – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Җитәкче** **А.А. Новиков**